Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2020 елның 5 ноябре №2/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлегендə муниципаль хезмəтнең вакантлы вазыйфасын билəүгə конкурс уздыру тəртибе турында нигезлəмəне раслау хакында» 2010 елның 15 июлендəге 9/4 номерлы карарына үзгəрешлəр кертү турында

«Россия Федерациясендə муниципаль хезмəт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендə, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлегендə муниципаль хезмəтнең вакантлы вазыйфасын билəүгə конкурс уздыру тəртибе турында нигезлəмəне раслау хакында» 2010 елның 15 июлендəге 9/4 номерлы карарына түбəндəге үзгəрешлəрне кертергə:

1.1. 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлегендə муниципаль хезмəтнең вакантлы вазыйфасын билəүгə конкурс уздыру тəртибе турында нигезлəмəдə (1 нче кушымта):

1 пунктта «Татарстан Республикасында муниципаль хезмəт турында» Татарстан Республикасы Законы белəн» сүзлəрен «Муниципаль хезмəт турында Татарстан Республикасы Кодексы белəн» сүзлəренə алмаштырырга;

8 пунктны түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«8. Конкурста катнашырга телəүчелəр конкурс комиссиясенə гариза бирə, аңа түбəндəге документлар кушып бирелергə тиеш:

1) муниципаль хезмəткə керү һəм муниципаль хезмəт вазыйфасын билəү турында үтенеч белəн гариза;

2) Россия Федерациясе Хөкүмəте тарафыннан вəкалəт бирелгəн федераль башкарма хакимият органы билгелəгəн форма буенча үз кулы белəн тутырылган һəм имзаланган анкета;

3) паспорт;

4) хезмəт шартнамəсе (контракт) беренче тапкыр төзелгəн очраклардан тыш, законнарда билгелəнгəн тəртиптə рəсмилəштерелгəн хезмəт кенəгəсе һəм (яисə) хезмəт эшчəнлеге турында белешмəлəр;

5) мəгариф турында документ;

6) хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ;
7) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык;
8) запаста булучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен хәрби исәпкә алу документлары;
9) муниципаль хезмәткә керүгә киртә булырлык авыру булмау турында медицина оешмасы бәяләмәсе;
10) муниципаль хезмәткә керүнең узган елдагы керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;
11) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган белешмәләр;
12) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Исләй авыл җирлеге
башлыгы В.П.Чернышев